ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е　　　　К А Р А Р

2021 елның «26» апреле　　　　№404

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2020 елның 16 гыйнварындагы 26 номерлы карары белән расланган үндүрт яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәмраслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карарына таянып, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2020 елның 16 гыйнварындагы 26 номерлы карары белән расланган үндүрт яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.5 пунктта 4 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;»;

2.5 пукнтта 6 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« Граждан хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклыклар;».

2. Әлеге карарны рәсми публикатор – «Лениногорские вести» газетасында бастырырга һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында

һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), гражданнар күзәтү өчен мөмкин булган мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча беренче урынбасары Г.А. Ивановага йөкләргә.

Җитәкче З.Г.Михайлова

И.Р.Хәйбрахманов

5-18-52